| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БАЛТАСИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

---

**РЕШЕНИЕ** — **КАРАР**

«09» июня 2026ел — № 33

**Гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары)уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Балтач шәһәр җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Балтач шәһәр җирлеге Советының 03.06.2020 N 146 карары белән расланган гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә (2023 елның 30 октябрендәге 28.06.2022 ел, № 59 үзгәреш белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 13 статьясындагы 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:: "Җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны үткәрү срогы муниципаль берәмлек халкына аларны үткәрү турында хәбәр иткән вакыттан алып җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр 10 календарь көн тәшкил итә.».

1.2. Нигезләмәнең 13 статьясына түбәндәге эчтәлекле 6 абзац өстәргә:: "Территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары буенча җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны үткәрү вакыты җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр басылып чыккан көннән алып җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр 31 календарь көн тәшкил итә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә baltasi.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзекләндерү, төзелеш, хокукларны яклау һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча даими комиссиягә йөкләргә (комиссия рәисе Каюмов М.Х.).

Балтач шәһәр җирлеге башлыгы Р.Р.Нотфуллин